**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм итү республика фонды турында**

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән затларга ярдәм оештыру максатларында, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының фонд оештыру-хокукый формасында Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм итү республика фонды төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм итү республика фондына «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруда катнашучы махсуслаштырылган оешма функцияләрен үтәү вәкаләте бирергә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Республика ярдәм фонды турында» 2017 елның 29 маендагы ПУ-447 номерлы Указына, преамбуласындагы «, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән затларга» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы исеменнән Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү республика фондын гамәлгә кую функциясен башкаручы вәкаләтле органын билгеләргә;

Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү республика фондын төзү һәм аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле карарлар кабул итүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Президентының «Республика ярдәм фонды турында» 2017 елның 29 маендагы ПУ-447 номерлы Указын үтәү йөзеннән

төзелгән Республика ярдәм фондын гамәлгә кую документларына әлеге Указ нигезләмәләрен исәпкә алып үзгәрешләр кертергә, шулай ук әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 09 март
№ ПУ-219